**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка», «Җырларым», «Бүреләр» шигырьләре**

**1.Муса Җәлилнең тоткынлыкта язылган шигырьләре кайсы исем белән атала?**

а) Моабит дәфтәрләре;

ә) Сайланма әсәрләр;

б) Әсирлектәге шигырьләр.

**2. «Кызыл ромашка» шигырендә егетнең батырлыгы ничек сурәтләнә?**

а) төнлә дә курыкмыйча сугыша;

ә) берүзе егерме биш укчыга каршы тора алмый;

б) яраланса да, чигенми.

**3. Ромашкалар бер-берсе белән ничек яши?**

а) елмаеп, хәл сорашып;

ә) хуш исле саф чыкларга күмелеп;

б) җилдә назланып.

**4.Муса Җәлилнең туган илен яратуы кайсы юлларда күренә?**

а) Җырым белән дусны иркәләдем,

Җырым белән җиндем дошманны.

ә ) Бар җырымны илгә багышладым,

Гомеремне дә бирәм халкыма.

б) Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,

Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

**5.Шагыйрь нинди җырлар турында яза?**

а) халык җырлары турында;

ә) әсирлектә җырланган җырлар турында;

б) үзенең язган шигырьләре турында.

***6.«Җәлил гомере җырга әверелде. Яшәү, Көрәш, Батырлык турындагы мәңгелек җыр ул хәзер. Ул җыр безгә тыныч кына ишәргә, хуш күңелле,***

***битараф булырга ирек бирми, безне янарга, дөрләргә өйрәтә, халыклар бәхете өчен көрәшкә әйди».* Бу фикерне кем әйтә?**

а) Константин Симонов;

ә) Роберт Миңнуллин;

б) Хәсән Туфан.

**7.Бу юллар Муса Җәлилнең кайсы шигыреннән?**

***Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә***

***Һәм үләргә кыю ир булып.***

а) «Кызыл ромашка» шигыреннән;

ә) «Бүреләр» шигыреннән;

б) «Җырларым» шигыреннән.

**8. Бүре нинди хайван?**

а) усал ерткыч;

ә) хәйләкәр хайван;

б) ярдәмчел хайван.

**9.«Бүреләр» шигыренә Муса Җәлил ни өчен Бүре образын керткән?**

а) бүреләрнең усаллыгын күрсәтү өчен;

ә) бүреләрнең кеше хәленә керә белгәнен күрсәтү өчен;

б) фашистларның явыз бүредән дә ерткычрак икәнен күрсәтү өчен.

**10. Шигырьдә, яраланган егетне кызганып, кайсы чәчәкләр елый?**

а) ромашкалар;

ә) миләүшә һәм лалә чәчәге;

б) умырзаялар.

**11. Ни өчен фашистлар яралы егетне газаплап, аннары ак каенга асып китәләр?**

а) фашистлар өчен туган илләрен яклап сугышкан яралы сугышчылар да куркыныч;

ә) үч алу өчен;

б) күбрәк кешеләрне үтерү өчен.

**12.Автор кешеләрне нәрсәләр белән чагыштыра?**

а) бүреләр белән;

ә) агачлар белән;

б) гөлләр белән.

**13. Карт бүре ни өчен яралы егет яныннан борылып китә?**

а) егетнең тере икәнлеген сизми;

ә) ашау өчен ат ите дә күп була;

б) бүре яралының сулышын тоя.

**14. Шигырь нәрсәне кисәтә?**

а) сугыш газаплары бүтән булмасын;

ә) кешеләр гел сугышып яшәсен;

б) бер-берләрен үтерсен.

**Ачкыч**

1. **А**
2. **Б**
3. **А**
4. **Ә**
5. **Б**
6. **Ә**
7. **Б**
8. **А**
9. **Б**
10. **Ә**
11. **А**
12. **А**
13. **Б**
14. **А**

# Бәяләү

**13-14 балл – “5”ле**
**11-12 балл – “4”ле**
**7-10 балл – “3”ле**